**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«21» октября 2020 № 390

«2021 елга «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 бүлегендәге 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү күпюнәлешле учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында”, 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм “Әтнә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2021 елга расларга:

беркетелгән «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын расларга;

балаларга өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-

педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. "Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә эш хакы индексы белән бер үк вакытта балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарының гамәлдә булуның барлык чорында яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе Ф. И. Гыймадиевка йөкләргә.

ТР Әтнә районы башкарма комитеты
житәкчесе вазыйфаларын башкаручы: М. Л. Халиков

Әтнә муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесенең
2020 ел, "21" октябрь, 390 нчы
карары белән расланды

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге дәүләт мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күпьюнәлешле дәүләт мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, 1 белем алучыга 1 елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белем алуның беренче елы | белем алуның икенче елы | белем алуның өченче һәм аннан соң килә торган еллары |
| Сәнгать-эстетика | авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |